ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2022 ел, 8 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешендәге 13 пунктында «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең» сүзләрен «гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең» сүзләренә алмаштырырга;

2) 21 статьяның 1 пунктында «, шулай ук сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтләр башкаручы җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 23 статьяда «, сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтләр башкаручы җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан , Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ 75-ТРЗ